ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. 2025 елда Татарстан Республикасы Конституция советы эшчәнлеге турында доклад.
3. «2025 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
4. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы.
5. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы.
6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 165-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 163-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 164-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 65 һәм 66 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 1133108-8 номерлы федераль

закон проекты хакында (федераль милектәге җир кишәрлекләрен комплекслы үсеш территорияләре чикләренә кертү тәртибен төгәлләштерү турында).

10. «Бөртекле ашлык турында» Россия Федерациясе Законының $17^1$ һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1148367-8 номерлы федераль закон проекты турында (бөртекле ашлыкның һәм бөртекле ашлыкны эшкәртү юлы белән алынган продуктларның сыйфатын һәм иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметын киңәйтү өлешендә).

11. «Җирләрне һәм җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

12. «Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 1138192-8 номерлы федераль закон проекты хакында (нотариаль гамәлләр башкарганда видеотеркәү чараларын куллану мәсьәләсе буенча).

13. Хөкүмәт сәгате: «Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 12 марты
№ 151-VII ДСП